| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ**
14 ноябрь 2022 ел

**КАРАР**
№ 155

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләр (вәкаләтләрнең бер өлешен) кабул итү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы составына керүче Балтач шәһәр җирлеге, Борбаш, Борнак, Югары Субаш, Карадуган, Куныр, Кече Лызи, Норма, Нөнәгәр, Пыжмара, Салавыч, Смәел, Сосна, Урта Көшкәт, Чепья, Шеңшеңәр, Шубан, Яңгул авыл җирлекләре Советларының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы составына керүче Балтач шәһәр җирлеге, Борбаш, Борнак, Югары Субаш, Карадуган, Куныр, Кече Лызи, Норма, Нөнәгәр, Пыжмара, Салавыч, Смәел, Сосна, Урта Көшкәт, Чепья, Шеңшеңәр, Шубан, Яңгул авыл җирлекләре Башкарма комитетларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына тапшыру турында тәкъдимнәрен кабул итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү өлешендә ритуаль хезмәтләр оештыру өчен шартлар тудыру;

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең эшчәнлек тәртибен билгеләү;

күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү буенча.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы составына керүче Балтач шәһәр җирлеге, Борбаш, Борнак, Югары Субаш, Карадуган, Куныр, Кече Лызи, Норма, Нөнәгәр, Пыжмара, Салавыч, Смәел, Сосна, Урта Көшкәт, Чепья, Шеңшеңәр, Шубан, Яңгул авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән әлеге карар кушымтасы нигезендә типлаштырылган формага туры китереп, төзелә торган килешүнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүен күздә тотып, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында бюджет законнары нигезендә 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетында акчалар карарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны Татарстан Республикасы Балтач район Советының гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, законлылылыкны һәм хокук тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район Советы рәисе,
Балтач муниципаль районы башлыгы Р.Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының 2022 елның
14 ноябрендәге 155 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач район Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының _______________ Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында килешү**

«___»______ 2022 ел ______________________
(авыл, шәһәр яки башкалар.)

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Башкарма комитеты исеменнән эш итүче, алга таба «Районның башкарма комитеты» дип аталучы җитәкче _______________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелә) бер яктан һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының ____________________ Башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының ____________________ Башкарма комитеты исеменнән эш итүче, алга таба «Җирлекнең башкарма комитеты» дип аталучы җитәкче[1] _______________ (фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелә) икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар, түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

**1. Килешү предметы**

Әлеге Килешүнең предметы - Җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан районның башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне тапшыру:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү өлешендә ритуаль хезмәтләр оештыру өчен шартлар тудыру, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең эшчәнлек тәртибен билгеләү, күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү буенча.

**2. Якларның хокуклары һәм бурычлары**

2.1. Җирлекнең башкарма комитеты Районның башкарма комитетына түбәндәгеләрне бирергә тиеш:

әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары һәм *матди ресурслар*[2] (алга таба - вәкаләтләр);

---

[1] Җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасы уставлары белән каралмаган (аларның башкарма комитетын җирлек башлыгы җитәкли) авыл җирлекләре өчен җирлек башлыгы күрсәтелә.

[2] Нигезләмәләр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен матди ресурсларны (муниципаль мөлкәтне) тапшыру кирәк булган очракта карала.

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат.

2.2. Җирлекнең башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

Районның башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләр үтәлешен, шулай ук әлеге Килешүнең 5.1 - 5.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә бирелгән финанс чараларыннан һәм *матди ресурслардан*[3] максатчан файдалануны контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

Район башкарма комитетыннан әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүматны алырга.

2.3. Районның башкарма комитеты бурычлы:

законнар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шул исәптән Җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан бирелгән финанс чараларын һәм *матди ресурсларны*[4] вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга гына максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

Җирлекнең башкарма комитетына квартал саен вәкаләтләрнең үтәлеше турында хисаплар, шулай ук аерым гарызнамәләр буенча Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат тапшырырга.

2.4. Районның башкарма комитеты хокуклы:

Җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын һәм *матди ресурсларны*[5] вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен алырга һәм кулланырга;

Җирлек башкарма комитетыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә рәвештә файдалану.

## 3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бюджет законнары нигезендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары *ай саен тигез өлешләр белән*[6] күчерелә.

3.3. Районның башкарма комитеты финанс чараларын максатчан файдаланмаган очракта, алар Җирлек башкарма комитеты таләбе буенча ун көн эчендә Җирлек бюджетына кайтарылырга тиеш.

## *4. Матди ресурсларны тапшыру тәртибе*[7]

4.1. Җирлекнең башкарма комитеты вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары

---

[3] Нигезләмәләр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен матди ресурсларны (муниципаль мөлкәтне) тапшыру кирәк булган очракта карала.

[4] Нигезләмәләр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен матди ресурсларны (муниципаль мөлкәтне) тапшыру кирәк булган очракта карала.

[5] Нигезләмәләр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен матди ресурсларны (муниципаль мөлкәтне) тапшыру кирәк булган очракта карала.

[6] Финанс чараларын күчерүнең башка тәртибе дә каралырга мөмкин (квартал саен, бер тапкыр).

[7] Нигезләмәләр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен матди ресурсларны (муниципаль мөлкәтне) тапшыру кирәк булган очракта карала.

турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законнын 35 статьясындагы 10 өлешенең 5 пункты нигезендә кабул ителгән жирлекнен вәкиллекле органы карарлары, нигезендә, әлеге Килешүне имзалаган көннән алып утыз көн эчендә муниципаль мөлкәтне тапшыра, ә Район башкарма комитеты түләүсез вакыты чикләнгән файдалану шартнамәсе нигезендә муниципаль мөлкәтне кабул итә.

4.2. Әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән түләүсез файдалану шартнамәсенең вакыты чикләнгән була һәм әлеге Килешүнең гамәлдә булу чорына төзелә.

4.3.Әлеге Килешүнең 4.1 пункты нигезендә тапшырылган матди ресурслардан файдалану тәртибе түләүсез файдалану шартнамәсе белән билгеләнә һәм анын мөһим шарты булып тора.

## 5. Вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тоту

5.1. Җирлекнең башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра, Район башкарма комитетыннан тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала.[8] Район башкарма комитеты Җирлекнең башкарма комитеты сораган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керeп йөрүен тәэмин итәргә тиеш.

5.2. Хисапларның формасы һәм аларны бирү тәртибе Җирлекнең башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә.

5.3. Тапшырылган финанс чараларын һәм матди ресурсларны кулланунын[9] контрольдә тоту Балтач муниципаль районы контроль-хисап органнары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының ________________ жирлеге тарафыннан, шул исәптән Җирлек башкарма комитеты таләбе буенча гамәлгә ашырыла.

## 6. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

6.1. Килешү 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

6.2. Әгәр Якларның берсе дә әлеге Килешүнең 6.1 пунктында каралган вакыт тәмамланырга кимендә 30 көн кала аны өзү турында белдермәсә, Килешү 2024 елга озайтылган дип санала.

## 7. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

7.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

бер яклы тәртиптә, Якларның берсе үз бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

7.2. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә язма рәвештә, анын

---

[8] Нигезләмәләр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен матди ресурсларны (муниципаль мөлкәтне) тапшыру кирәк булган очракта карала.

[9] Нигезләмәләр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен матди ресурсларны (муниципаль мөлкәтне) тапшыру кирәк булган очракта карала.

фаразланган гамәлдә булу датасына кадәр кимендә 30 көн кала икенче Якка җибәрелә.

7.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, Җирлекнең башкарма комитеты Район башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди ресурсларны[10] кире кайтара.

## 8. Якларның җаваплылыгы

8.1.Әлеге Килешү буенча бурычларын үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

8.2. Якларның берсе әлеге Килешү буенча үз бурычларын үтәмәгән өчен гаепле Як икенче Якка әлеге Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

8.3. Штраф түләү Якларны алга таба әлеге Килешү буенча бурычларны үтәүдән азат итми.

## 9. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл ителә.

Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедураларын уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

## 10. Йомгаклау нигезләмәләре

10.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм өстәмә килешү белән язма рәвештә рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Килешү бер үк юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелгән, һәр Як өчен бер нөсхә.

## 11. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Балтач район башкарма комитеты<br>җитәкчесе | Татарстан Республикасы<br>Балтач муниципаль районының<br>________________ Башкарма комитеты<br>җитәкчесе[11] |
| ______________________________ | ______________________________ |

---

[10] Нигезләмәләр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен матди ресурсларны (муниципаль мөлкәтне) тапшыру кирәк булган очракта карала.

[11] Җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасы уставлары белән каралмаган (аларның башкарма комитетын җирлек башлыгы җитәкли) авыл җирлекләре өчен җирлек башлыгы күрсәтелә.